**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2022 елның 28 марты** **28-РС номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 25 октябрендәге 81-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды**:**

1. Хәвеф-хәтәр индикаторлары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 25 октябрендәге 81-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары белән расланган, әлеге карарга кушымта нигезендә,Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда индикатив күрсәткечләргә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районы Советының*
*2022 елның 28 мартындагы 28-РС номерлы*
*карарына кушымта*

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда индикатив күрсәткечләр исемлеге**

1) хисап чорында үткәрелгән планлы тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;
2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;
3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны,;
4) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;
5) хисап чорында үткәрелгән КНМның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;
8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;
9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;
12) хисап чорында тикшерү (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
13) прокуратура органнарына хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында гаризалар саны;
14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
15) хисап чоры ахырына һәр риск категориясе буенча хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны;
16) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;
17) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;
18) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;
19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;
20) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннаналарны карау йомгаклары буенча контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгару турында яисә контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлдә түгел дип тану турында Карар кабул ителгән судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләр саны,;

21) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;
22) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъвалау турында, алар буенча гариза бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында Карар кабул ителгән, дәгъва гаризалары саны,.;
23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән, аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советының
2022 елның _______ ____ номерлы
карарына кушымта

**Автомобиль транспортында һәм Лаеш муниципаль районында юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлегене**

| Индикаторның исеме | Сайланган параметрның нормаль торышы (бәяләү критерийлары), үлчәү берәмлеге (булганда) | Риск индикаторы күрсәткече |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| **Индикаторның исеме** | 5-10, данә. | < 5 д.яисә<br>> 10данә. |
| **Индикаторның исеме** | юк | әйе |
| **Индикаторның исеме** | ........Федераль закон нигезендә билгеләнә | нормаль параметрларны 10%тан артыкка киметү яки арттыру |